**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АКТАНЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

пр. Ленина, дом 17, с.Актаныш, 423740

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

Ленин пр.,17 йорт, Актаныш ав., 423740

Тел. (85552) 3-44-22, факс (85552) 3-44-14, E-mail: mail.Aktanish@tatar.ru , www.aktanysh.tatarstan.ru

---

РАСПОРЯЖЕНИЕ　　　　　　　　　　　　　　　　　　　　　　　　БОЕРЫК

______________　　　　　　　　　　　　　　　　　　　　　　　　№ _______

Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы территориясендә муниципаль җир контролен уздырганда тикшерү кәгазе (контроль сораулар исемлеге) формасын раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 июлендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 248-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә мәҗбүри таләпләр турында» 2020 елның 31 июлендәге 247-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Тикшерү кәгазьләрен (контроль сораулар исемлекләрен) эшләүгә һәм раслауга таләпләрне раслау турында» 2017 елның 13 февралендәге 177 номерлы карарына таянып, Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты **КАРАР ИТТЕ:**

1. Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы территориясендә муниципаль җир контролен уздырганда тикшерү кәгазьләренең (контроль сораулар исемлекләренең) формаларын кушымта нигезендә расларга.
2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмати рәсми порталы»нда, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә һәм Актаныш муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга.
3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең икътисад буенча урынбасарына йөкләргә.

Җитәкче　　　　　　　　　　　　　　　　　　　　　　　　Р.А.Ильясов

**Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы**

---

Муниципаль җир контроле

**Тикшерү кәгазе (контроль сораулар исемлеге)**

1. Юридик зат исеме, шәхси эшкуарның фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта)________________________________________
2. Тикшерү кәгазен тутырып, планлы тикшерү үткәрү урыны____________________
3. Җитәкченең күрсәтмә яки боерыгы реквизитлары________________________
4. Тикшерүнең хисап номеры һәм тикшерүнең хисап номерын бирү датасы ________________________________________
5. Планлы тикшерү уздыра һәм тикшерү кәгазен тутыра торган мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасының (аның территориаль органы) вазыйфаи затының фамилиясе һәм инициаллары ________________________________________
6. Юридик затларны һәм индивидуаль эшкуарларны планлы тикшерү предметы әлеге тикшерү кәгазенә кертелгән сораулар исемлеге белән чикләнә.________________
7. Юридик зат, шәхси эшкуар тарафыннан тикшерү предметы булган мәҗбүри таләпләрнең үтәлүен яки үтәлмәвен раслый торган мәҗбүри таләпләрнең эчтәлеген чагылдыручы сораулар исемлеге: ________________________________________

| т/б | Мәҗбүри таләпләрнең эчтәлеген чагылдыручы сораулар исемлеге | Мәҗбүри таләпләр билгеләнгән структур берәмлекләрен күрсәтеп, норматив хокукый актлар реквизитлары | Сорауга җавап (әйе/юк/таралмый) |
|---|---|---|---|
| 1 | Авыл хуҗалыгы җитештерүен алып бару яки авыл хуҗалыгы җитештерүе белән бәйле башка эшчәнлекне гамәлгә ашыру өчен җир кишәрлеге кулланамы? | Россия Федерациясе Җир кодексының 7, 42 статьялары | |
| 2 | Җирләрнең уңдырышлылыгын торгызу чаралары үткәреләме: | Россия Федерациясе Җир кодексының 13, 42 статьялары, «Авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрнең уңдырышлылыгын тәэмин итүне дәүләт җайга салуы турында»1998 елның 16 июлендәге 101-ФЗ номерлы Федераль законның 1, 8 статьялары | |
| 2.1 | агротехник чаралар? | | |
| 2.2 | агрохимик чаралар? | | |
| 2.3 | мелиоратив чаралар? | | |
| 2.4 | фитосанитар чаралар? | | |
| 2.5 | эрозиягә каршы чаралар? | | |
| 3 | Җирләрнең капланувы: | | |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 3.1 | агачлар белән? | Россия Федерациясе Җир кодексының 13 статьясындагы 2 өлешенең 3 пункты | |
| 3.2 | куаклыклар белән? | | |
| 3.3 | чүп үләннәре белән? | | |
| 4 | Төзелеш, мелиорация, тикшеренү һәм башка эшләрне башкарганда, хуҗалыкта яисә үз кирәк-яраклары өчен файдаланыла торган җирләрне рекультивацияләү уздырылганмы? | Россия Федерациясе Җир кодексының 13 статьясындагы 5 өлеше, Россия Табигать министрлыгының 22.12.1995 ел, № 525/67 боерыгы белән расланган, җирләрне рекультивацияләү, туфракның уңдырышлы катламын алу, саклау һәм рациональ файдалану турындагы төп нигезләмәләрнең 5 пункты (Россия Юстиция министрлыгы тарафыннан 29.07.1996, 1136 номерлы теркәү номеры) | |
| 5 | Юл куялармы: | Россия Федерациясе Җир кодексының 42 статьясы. «Әйләнә-тирә мохитне саклау турында» 1996 елның 10 гыйнварындагы 7-ФЗ номерлы Федераль законның 43 статьясы; | |
| 5.1 | пычрану? | | |
| 5.2 | ярлылану? | | |
| 5.3 | деградация? | | |
| 5.4 | бозу? | | |
| 5.5 | җирләрне һәм туфракны юкка чыгару? | | |
| 5.6 | җиргә һәм туфракка башка тискәре йогынты? | | |
| 6 | Мелиорация эшләрен башкарганда мелиорация эшләрен уздыру проекты үтәләме? | «Җирләрне мелиорацияләү турында» 1996 елның 10 гыйнварындагы 4-ФЗ номерлы Федераль законның 25 статьясы | |

| т/б | **Мәҗбүри таләпләрнең эчтәлеген чагылдыручы сораулар исемлеге** | **Мәҗбүри таләпләр билгеләнгән структур берәмлекләрен күрсәтеп, норматив хокукый актлар реквизитлары** | **Сорауга җавап (әйе/юк/таралмый)** |
|---|---|---|---|
| 7 | Мелиоратив системалар һәм саклагыч урман үсентеләре төзек хәлдә тотыламы? | «Җирләрне мелиорацияләү турында» 1996 елның 10 гыйнварындагы 4-ФЗ номерлы Федераль законның 29 статьясы | |
| 8 | Мелиорацияләнә торган (мелиорацияләнгән) җирләрдә элемтә линияләрен, электр тапшыруларын, труба үткәргечләрен, юлларны һәм башка объектларны төзү һәм (яки) эксплуатацияләү эшләрен килештерү бармы? | «Җирләрне мелиорацияләү турында» 1996 елның 10 гыйнварындагы 4-ФЗ номерлы Федераль законның 30 статьясы | |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 9 | Җитештерү һәм куллану калдыкларын туфракта урнаштыру рөхсәт ителәме? | «Әйләнә-тирә мохитне саклау турында» 2002 елның 10 гыйнварындагы 7-ФЗ номерлы Федераль законның 51 статьясындагы 2 өлеше | |
| 10 | Җир кишәрлегендә туфрак катламын бозуга бәйле эчке эшләр башкаруга рөхсәт бармы? | Россия Табигать министрлыгының 22.12.1995 ел, № 525/67 боерыгы белән расланган, җирләрне рекультивацияләү, туфракның уңдырышлы катламын алу, саклау һәм рациональ файдалану турындагы төп нигезләмәләрнең 11 пункты | |
| 11 | Туфрак катламын бозуга бәйле рәвештә төзелеш эшләре башкарылганда туфракның уңдырышлы катламы алындымы? | Россия Федерациясе Җир кодексының 13 статьясындагы 4 өлеше, Россия Табигать министрлыгының һәм Роскомземның 22.12.1995 ел, № 525/67 боерыгы белән расланган, җирләрне рекультивацияләү, туфракның уңдырышлы катламын алу, саклау һәм рациональ файдалану турындагы төп нигезләмәләрнең 8 пункты | |
| 11.1 | Бозылган җирләрне рекультивацияләү яки аз продуктлы җирләрне яхшырту өчен туфракның өске катламы файдаланылганмы? | | |

1 Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2001, № 44, ст4147; 2006, № 52 (1 өлеш), 5498; 2008, № 29 (1 өлеш), 3418; 2010, № 30, 3998; 2011, № 1, 54 ст., 2014, №30 (1 өлеш), 4235 ст., 2016, №27 (2 өлеш), 4267 ст.

2 Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 1998, № 29, 3399 ст., 2009, №1, 17 ст., 2016, №15, ст.2066;

3 Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2002, № 2, 133 ст., 2008, № 29, (1 өлеш), 3418 ст.;

4 Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 1996, № 3, 142 ст., 2003, № 2, ст. 167; 2004, №35, ст. 3607; 2008, №29 (1 өлеш), 3418 ст.; 2016, № 15, ст. 2066.

"___" _______________ 20 ел
(тикшерү кәгазе тутыру датасы күрсәтелә)

_____________ _____________ ______________________________

( вазифасы) (имзасы) (тикшерү кәгазен тутырган затның Ф.И.А.)